ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БЕТЬКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422649, с. Бетьки,
ул. Мира, дом 11

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘТКЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422649, Бәтке авылы,
Тынычлык урамы, 11 нче йорт

Тел.: (84361) 26235, факс: (84361) 26235, e-mail:**bet.rs@tatar.ru**, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.r

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2018 елның 17 августы** **Бәтке ав.** **№ 15**

Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитетының “2018-2019 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге территориясендә терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау программасын раслау турында "2018 елның 13 июнендәге 10 номерлы карарын гамәлдән чыгару турында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2018 елның 7 августындагы 16086508201800007 номерлы хокукый экспертиза бәяләмәсе нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 7.1 пункты, 3,4 өлеше, 48 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 5 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Бәтке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитетының «2018-2019 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге территориясендә терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау программасын раслау турында»2018 ел, 13 июнь, 10 нчы номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авылы,Ленин урамы,4 йорт; Яншык авылы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 23 йорт; Кече Укмас авылы, Гагарин урамы, 9Б йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет”

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы Ф.М.Динмөхәммәтов